**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

09 апреля 2026 ел № 9/1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советының кайбер карарлары үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатында, Калмия авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Калмия авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 26 сентябрендәге 7/5 номерлы карар.
- «Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү хакында һәм район керемнәре, мөлкәте турында белешмәләр бирү һәм урнаштыру тәртибе турында, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү һәм урнаштыру тәртибе турында Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 01декабрендәге 8/2 номерлы карар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм махсус стендларда, «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Калмия авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Закиров